КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 21 сентябрь г.Казань № 869

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча күпфункцияле үзәк» дәүләт бюджет учреждениесен оештыру турында» 2013 ел, 28 февраль, 136 нчы карарына үзгәреш кертү хакында

«Татарстан Республикасында дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча күпфункцияле үзәк» дәүләт бюджет учреждениесе бүлекләрендә һәм филиалларында дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү нәтиҗәлелеген күтәрү максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча күпфункцияле үзәк» дәүләт бюджет учреждениесен оештыру турында» 2013 ел, 28 февраль, 136 нчы карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 29 апрель, 293 нче; 2014 ел, 24 декабрь, 1020 нче; 2016 ел, 2 март, 128 нче; 2016 ел, 26 декабрь, 987 нче; 2017 ел, 8 сентябрь, 642 нче; 2017 ел, 30 октябрь, 820 нче; 2018 ел, 24 июль, 585 нче; 2019 ел, 22 гыйнвар, 30 нчы; 2019 ел, 29 март, 235 нче; 2019 ел, 19 июль, 606 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып), 5 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«5. Учреждение хезмәткәрләренең иң чик штат санын вазыйфаи окладлар буенча 13 282 867 сум күләмендәге айлык хезмәт өчен түләү фонды белән 992 берәмлек итеп билгеләргә.».

2. Бу карарның гамәле 2019 елның 1 августыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасының Икътисад министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин